**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КАРАР**

09.10.2018 Балык Бистәсе штп. №47ри

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 31 маендагы 38ри номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында хезмәт тикшерүләре оештыру турындагы Инструкциягә үзгәрешләр кертү хакында**

Муниципаль норматив-хокукый актны гамәлдәге законнарга ярашлы итү максатларында, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 193 маддәсенә туры китереп,

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 31 маендагы 38ри номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетында хезмәт тикшерүләре оештыру турындагы Инструкциягә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

31 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Дисциплинар җәза, чикләүләр һәм тыюларны, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен дисциплинар җәзадан гайре, гаеп эш кылынган көннән алты айдан соң кулланыла алмый, ә ревизия, финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү яисә аудитор тикшерүе нәтиҗәләре буенча – аны кылган көннән ике елдан соң. Чикләүләр һәм тыюларны, коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән бурычларны үтәмәгән өчен дисциплинар җәза гаеп эш кылынган көннән өч елдан соң кулланыла алмый. Җинаять эше буенча эш алып бару вакыты күрсәтелгән срокларга кертелми.”.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Л. Исланов